

10 декабрьдә Мордовиянен А.С.Пушкин исемендәге милли китапханәсендә «Антитеррорнын кыска метры» мәгариф оешмалары медиаторкемнәре һәм медиаvзәкләре арасында ин яхшы террорчылыкка каршы контентка Ботенроссия конкурсакция жинvчеләрен бvләкләv тантанасы vтте. Конкурс Ватан Геройлары конена багышланган иде.

Анын максаты яшьләрдә традицион Россия рухиәхлакый кыйммәтләре нигезендә террорчылыкка каршы доньяга караш, террорчылык идеологиясен кабул итмәv һәм аны пропагандалауга тотрыклылык формалаштыру булды.       Ижади бәйгедә Россиянен 7 тобәгеннән - Мордовия, Татарстан, Мәскәv, Санкт-Петербург, Тvбән Новгород, Пенза һәм Ульяновск олкәләреннән 300дән артык кеше катнашты. Йомгаклар буенча 22 конкурс эше ин яхшылар дип танылды.

Бvләкләv тантанасында ин яхшы эшләрнен авторларын Россия Юстиция министрлыгынын Урта Идел институты филиалы (Средне-Волжский институт (филиал) ВГУЮ (РПА Минюста России)) директоры Галина Кулешова сәламләде.

Гран-при ияләренә дипломнарны Мордовия Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия эшчәнлеген тәэмин итv бvлеге модире (Отдел по обеспечению деятельности Антитеррористической комиссии в Республике Мордовия Администрации Главы РМ и Правительства РМ) Сергей Шамин тапшырды.




«Терроризмнын дине һәм милләте юк» номинациясендә Гран-прины Санкт-Петербург институты (филиалы) ВГУЮ (РПА Минюста России) коллиятенен «Куркынычсызлык һәм хокук лабораториясе» студентлар берләшмәсе авторлары коллективы алды.

«Террорга каршы геройлар» номинациясендә Гран-прига Ковыл-кино районы Краснопресненский урта гомуми белем бирv мәктәбе филиалы- Мамолаевка урта гомуми белем бирv мәктәбеннән Карина Кузнецова лаек булды.

«Террорга каршы геройлар» номинациясендә Гран-при Зубово-Поляна районы Явас урта

гомуми белем бирv мəктəбеннəн информатика укытучысы Алексей Автайкинга (фотода) тапшырылды.
Тантанада «Террорчылыкка каршы Геройлар», «Террорчылыкнын дине һəм миллəте юк», «Исəн калу очен белергə» һəм «Куркусыз яшə» кебек конкурснын торле номинациялəрендə мəктəп укучылары һəм белем бирv оешмаларынын тулы коллективлары беренче, икенче һəм оченче дəрəжə дипломнар белəн бvлəклəнделəр.
Бvлəклəvлəр концерт номерлары белəн бергə vрелеп барды.

**Наилə НАСЫРОВА**